# Чишмә башы

## Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе

**Ноябрь, 2024 нче ел**

**Бу санда**
- 24 нче ноябрь – Әниләр көне
- Гаилә – җылы учак
- Яшь хәбәрчеләр ни яза?




## Хөрмәтле әниләребез!

Сезне чын күңелдән иң күркәм бәйрәм – Әниләр көне белән котлыйбыз! Әни – һәркемнең тормышындагы иң мөһим кеше. Бу көн сезнең өчен елмаю, җылы сүзләр һәм иң матур теләкләр белән тулсын. Балаларыгыз үзләренең уңышлары, казанышлары белән шатландырып торсыннар һәм бәхетле кешеләр булып үсссеннәр. Сезгә һәм гаиләгезгә сәламәтлек, иминлек һәм тынычлык телим.

Тормышыгызның һәр минуты бәхет һәм шатлык белән тулы булсын! Балаларыгыз уңышлары белән сөендереп торсын!

***Җирдә кояш нуры балкыгандай,***
***Сез балкыйсыз безнең күңелдә.***
***Тормышыбыз сезнең белән матур,***
***Рәхмәтлебез сезгә гомергә.***

**Ихтирам белән, Садриева Нурия Зиннуровна**

## Ышанычың акларммын!

Әнидән дә изге, әнидән дә кадерле кеше җир йөзендә юктыр ул. Әни – һәркем өчен бик кадерле кеше. Ул булганда дөньялар яктыра, өйләр җылынып китә.

Минем әнием – Зәмзәмия исемле. Ул – минем сердәшчем, юатучым. Әнием пешергән ризыклардан авыз итсәң, телеңне йотарсың. Ул аларны бар күңел җылысын кушып әзерли.

Без гаиләдә өч бала. Әнием барыбызны да бертигез ярата. Безгә дус-тату булырга, эшне яратырга куша, киңәшләрен бирә.

## Әниемнең гөлләре.

Тәрәзә төбендә үсә
Әниемнең гөлләре.
Өебезне балкыталар,
Нидә икән серләре?
Әнием көн дә аларны
Үстерә сөеп, карап.
“Гөлкәйләрем”, - дип эндәшә,
Аларга шулай назлап.
Сөеп, сыйпап эндәшкәнне
Гөлләр дә яраталар.
Хәтта салкын кышларда да
Өйгә ямь тараталар.
Әниемне дә чәчәккә
Охшатамын кайчакта.
Яшәрә генә бара ул,
Гөлләре аткан чакта.

**Минһаҗева Зәлия, 5 нче сыйныф укучысы**

Мин әниемне бик яратам. Барлык әниләрне бәйрәм белән котлыйм. Сәламәт һәм озын гомерле булыгыз, кадерле Әниләр!

Тап төшермәм, әни, намусыма,
Ышанычың синең акларммын.
Күңелемдәге иң кадерле сүзне
Синең өчен генә саклармын.

**Бикбаев Ильяс, 7 нче сыйныф укучысы**

## Мәктәбебездә Әниләр көне уңаеннан “Гаилә – жылы учак” дигән темага бик матур чара узды.








### Әнием - Укытучы

Минем әнием иң хөрмәтле, кирәкле, авыр, ләкин мактаулы һөнәр иясе, ул - Укытучы.
Ул инде утыз елга якын мәктәптә башлангыч сыйныф укуыларына белем бирә. Башлангыч сыйныф укытучысы баланы хәреф танырга, язарга, санарга гына өйрәтеп калмый, ә итагатьле, миһербанлы-шәфкатьле булырга да өйрәтә. Аны укучылары хөрмәт итәләр һәм яраталар. Әнием белән укучылары арасында бервакытта да аңлашылмаучылык килеп чыкмый, килеп чыга калса да, әнием алар белән уртак тел таба, укучыларның хәлләренә керә. Әти-әниләр белән дә аңлашып, килешеп эшли ул. Әнием - бөтен барлыгы белән нечкә күңелле, олыларны-олы, кечеләрне-кече итә белгән, яманлыкның нәрсә икәнен дә белмәгән кеше.

Минем әни тикмәгә генә укытучы һөнәрен сайламаган. Беренчедән, мәктәптә аңа үз һөнәрләренең чын осталары, хезмәтләренә жаны-тәне белән бирелгән, бөтен тормышларын балалар укытуга багышлаган укытучылар белем биргән.

Икенчедән, олы ихтирамга лаек булган Фәния әбием дә гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган укытучы.

Әнием һәрвакыт үзенең укучыларын яратып, сагынып, хөрмәт белән искә ала һәм алар белән аралашып тора.

Әнием – өебезнең нуры, барыбыз өчен дә бик кадерле кеше. Әтием Марат белән алар безне, улларын, бик яратып һәм кадерләп үстерәләр. Өйдәге чисталык, нур, жылылык – барысы да әниемнән. Бүгенге көндә музыка көллиятендә белем алучы абыем Самат белән әти-әниебезгә булышып, өйдәге эшләрне бергәләп башкарабыз. Әнием безне бик ярата, без дә аның белән горурланабыз.

Әни булганга, без бик бәхетле,
Әни белән якты көнебез.
Балаларың булганга сөенәсеңдер,
Сиңа озын-озак гомер телибез.

**Минһажев Ильяс, 9 нчы сыйныф укучысы**

## *Барлык әниләрнең балаларга үгет-нәсыйхәте*

***1. Сезгә иң якын кешеләр ата-аналарыгыз. Шуның өчен аларга һәрвакыт итәгатьле булыгыз, эштә һәм сүздә аларга каршы килмәгез.***
***2. Ата-аналарыгыз алдында әдәпле булыгыз. Аларның сүзләрен яхшы тотыгыз. Алар белән кычкырмый гына, әдәп белән ачык итеп сөйләшегез.***
***3. Дөньяда вакытта шатлыкларны һәм кайгыларны уртаклашыр өчен якын һәм ышанычлы кешеләр кирәк була. Балалар өчен әти-әнисеннән дә ышанычлырак кеше һич булмас. Алар баланың шатлыгы өчен үзеннән дә артыграк сөенәләр, ә кайгы-хәсрәтләрен жиңеләйтү өчен кулларыннан килгән чараларның бөтенесен эшләргә тырышалар. Шуның өчен серләрегезне әти-әниләрегез белән уртаклашыгыз.***

***Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык та шулкадәр көчле була.***




## Гаилә – җылы учак




Безнең гаиләбез зур. Йортка җылылык бирүче әтиебез, яктылык бирүче әниебез, тәмле телле әбиебез һәм шатлык таратучы алты бала: ике малай һәм дүрт кыз бик бәхетле тормышта яшәп ятабыз.

Рәшит бабам белән Венера әбием төп йорттан башка чыгып урнашкан нигез бәхетле булган. Яңа урында йорт җиткереп, өч бала үстергәннәр алар: ике малай һәм бер кыз. Әтием Раил – икенче малай. Безнең нәселдә шулай кабул ителгән: төпчек малай әти-әни янында яши. Әтием дә традицияне бозмый, төп йортта яшәп кала. Әти-әнисе белән киңәшеп, зур итеп заманча өй төзиләр, бәхетле нигезгә әнием килен булып төшә.

Яшьләр өлкәннәр сүзеннән чыкмыйча, өлкәннәр яшьләргә үрнәк күрсәтеп, матур итеп яшәп китәләр. Чынлап та, мин үземне белә башлаганнан алып, безнең өйдә һәрвакыт зур өстәлдә чәй табыны әзерләнә, кемнедер каршылыйлар, яки озаталар. Әтинең туганнарына да әнинекеләргә дә бер төрле караш бездә. Карап торсаң, бөтен кеше бертуган кебек. Әтиемнең абыйсының ике малае да авылны бик яраталар. Без бөтен эшләрне күмәкләп башкарабыз. Бертуганнарым да, икетуганнарым да минем өчен бик кадерле. Өебездәге җылылык, игътибар, аңлашып яшәү шулкадәр рәхәтлек бирә, һәр кешегә елмаеп карыйсы, матур сүзләр генә әйтәсе килә. Мин мәктәптән дә гаиләбезнең җылы учагын сагынып кайтам. Барыбыз да өстәл янына кичке ашка җыелгач, һәрберебез бүгенге уңышлары турында сөйли. Шундый рәхәт минутлар була ул.

Әтием - үзэшмәкәр минем, аның эше авыр һәм җаваплы. Ул һәрбер эшне бик уйлап эшли. Кем генә аңа үтенеч белән килсә дә, ярдәм итә ул. Рәхмәт сүзләре генә ишетеп яши. Йортыбыздагы тәртип, уңайлы яшәү шартлары - барысы да аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Әниебезне җылылык чәчүче якты кояш белән тиңлим мин. Шулкадәр уңган, сабыр, бишебезгә дә матур сүзләр белән генә эндәшә, әтиебез белән әбиебезне дә бик хөрмәтли ул. Чын хатын-кыз образы минем әнием кебек буладыр, минемчә. Абыем Раяз әтием белән бергә йорт эшләрен караса, мин әнием янында аш-су әзерләргә яратам. Кечкенә энем, сеңелләремне без барыбыз да бик яратабыз. Алар шундый шук–шаяннар, әбием аларны: “Алтын алмаларым,- дип атый. – Алтын алмаларга әкияттәге бай да кызыккан”,- ди.

Ярату, кичерү һәм сабырлык яшәгән йортыбызда гаилә учагының җылысы, яктысы һәрвакыт барыбызга да җитәрлек булсын. Шундый матур гаилә булып, әти-әниебезнең пар канаты астында яшәргә насыйп булса иде безгә. Киләчәктә без дә шундый матур гаиләләр корып, әти-әниләребезне хөрмәтләп яши алсак иде.

**Камалиева Ралинә, 9 нчы сыйныф укучысы**

## Гаилә – изге йорт

Гаиләм-җылы учагым.
Мине саклаучы
Ачы җилдән, бураннардан
Мине яклаучы.

Әнием, әтием! Нинди җылы сүзләр!Гаилә дигәч, күңелемә якын әлеге сүзләрне әйтәсем килә.

Әтием Айрат исемле. Ул Балык Бистәсе районында туган. Нинди генә эшкә тотынса да, җиренә җиткереп башкара. Алтын куллы кеше ул минем әтием. Безгә дә гел ярдәм итәргә генә тора.

Әнием Гөлназ исемле. Ул Арча эшчеләр посёлогында туып-ускән. Әнием бик сабыр, эшчән, матур һәм ярдәмчел. Авырганда терелергә булышучы, авыр вакытта киңәшләрен бирүче кеше.

Минем гаиләмдә иң олы кеше - дәү әнием. Ул - Фәния исемле. Дәү әнием йомшак куллы, нечкә күңелле кеше. Әби безнең өчен икенче әниебез.

Әминә-минем сеңелем. Аңа сигез яшь. Ул рәсем ясарга ярата. Сеңелем бик шук булса да, мин аны бик яратам.

Гаилә ул - йорт кебек. Нигезе нык булмаган йорт җимерелә. Ә мин үзебезнең йортның җимерелүен теләмим. Әтием белән әнием-йортның тоткасы, ә без - аның көзгесе.

Һәрбер бала әти-әни җылысын тоеп, бәхетле гаиләдә яшәсен иде.

**Насыйбуллина Раяна, 6 нчы сыйныф укучысы**

# Яшь хәбәрчеләр ни яза?

## Г. Курсави исемендәге музей

2024 елның август аенда туган авылым Югары Курса тарихында зур вакыйга булды: Габденнасыйр Курсави исемендәге музей ачылды. Г. Курсави Югары Курсага мәдрәсә салдыра, имам-хатыйб, мөдәррис булып, шәкертләр җыеп укыта. Ялкынланып эшли ул. Аның максаты туган халкын рухи яңарту, аңын уяту, бәхетле итү була. Хөр акыл, фикер иреге таләп иткән мөдәррискә иске карашлылар үз җирендә дә тынычлык бирмиләр.

Курсави халыкның киләчәген прогресс һәм мәгърифәт юлында, фәнни белемнәр һәм мәдәният таратуда күрә. Аның бу фикерләре бүген дә әһәмиятле. Курсавиның кешене хакимнәр боерыгын сукырларча үтәүче хокуксыз һәм аңгыра хайванга әйләндерергә ярамый, дигән фикере дә бик кыю һәм үлемсез. Шунысы сөендерә, Габденнасыйр Курсави безнең көннәргә кадәр танылган шәхес булып килеп җитте һәм мәңгеләште.

Тантаналы чарага ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов кайткан иде. Шулай ук район башлыгы Илшат Нуриев катнашты.

**Загриева Зәринә, 9 нчы сыйныф укучысы**



## Сүзлекләр һәм энциклопедияләр көне

Китап – кешенең хәтере, юлдашы, киңәшчесе, ярдәмчесе, укытучысы. Китапсыз халык - тарихсыз халыкка әйләнгән, ә тарихын оныткан халыкның киләчәге өзелгән.

Китапханә - бик күп мәгълүмат, тарихи ядкарьләр, аң-белем, мәгърифәт тупланган йорт. Мәктәбебезнең бер бүлмәсенә урнашкан китапханәсенең ишекләре бикләнеп тормый. Безнең, 6 нчы сыйныф укучыларының да яраткан урыны ул - китапханә. Шушы көннәрдә без китапханәгә чираттагы чарага кердек. Бирedә китапханәче Нурия Зиннуровна "Сүзлекләрнең тылсымлы дөньясы" темасына багышланган әңгәмә үткәрде. 22 нче ноябрь - Сүзлекләр һәм энциклопедияләр көне буларак билгеләп үтелә.

Сүзлекләр һәм энциклопедияләр бәяләп бетергесез ярдәм күрсәтәләр. Чара барышында китапханәче сүзлекләрнең төрләре, алардан дөрес файдалану һәм китапларның әһәмияте, аларны саклап тотуның мөһимлеге турында сөйләде.

Сүзлекләрнең мөмкинлекләре чиксез. Алардан файдалансак, күзалларыбыз да киңрәк, белемебез дә ныграк булачак.



**Ахунҗанова Зилә, 6 нчы сыйныф укучысы**

## “Ясалма интеллект һәм кеше”





Узган уку елыннан бирле мәктәпләрдә “Мөһим сөйләшүләр” темасына әңгәмәләр уза. Чираттагысы – “Ясалма интеллект” темасына багышланды. Ул безнең тормышны яхшырак итә торган катлаулы, күзгә күренми торган алгоритм. Хәтта дөньяның бөек галимнәренә караганда да акыллырак һәм нәтиҗәлерәк. Мәсәлән, ясалма интеллект санаулы секундлар эчендә гигант күләмдәге мәгълүматны эшкәртә һәм алардан нәтиҗәләр ясый ала. Ул мәгълүматны татар телендә яза башлаган, һәр телләгән кеше аның ярдәме белән татарча төрле текстлар, мәкаләләр, игъланнар язып карый ала. Ясалма интеллектның татарча язу мөмкинлекләре турында эшмәкәрләр һәм төрле компанияләрнең югары квалификацияле белгечләренең vk.ru платформасында хәбәр ителә.

“Ясалма интеллект һәм кеше” дип аталган класс сәгатендә без күп мәгълүмат алдык, заманча белем бирүдәге әһәмияте белән таныштык.

**Амирова Әминә, 5 нче сыйныф укучысы**

## “Китапка икенче тормыш бүләк ит!” акциясе



22 июльдән 22 октябрьгә кадәр Татарстанда “Китапка икенче тормыш бүләк ит” дип аталган хәйрия акциясе узды. Әлеге чара кысаларында һәркем үзендә булган яхшы хәлдәге кызыклы китаплар, дәреслекләрне мәктәп китапханәләренә тапшыра ала иде.

Акция барышында кызыклы әдәби әсәрләр, махсус белешмәләр, дәреслекләр алып килүчеләр булды. Бу акциядә безнең класс укучылары да актив катнашты. Мин үзем китапханәгә өч китап алып килеп тапшырдым.

**Хәсәнов Раил, 5 нче сыйныф укучысы**

## Халыкара китапханәләр көне






25 нче октябрь көнне Халыкара китапханәләр көне билгеләп үтелде. Китапханәләр һәр мәктәптә дә бар. Укучыларга китап дөньясына юл ачуда аның роле әйтеп бетергесез. Китап укыган бала белемле, аның дөньяга карашы нык була.

Әлеге дата уңаеннан директор киңәшчесе укучылар өчен китапханә белән танышу-таныштыру әңгәмәсе уздырды. Укучылар әңгәмә барышында китапларның барлыкка килү тарихын белделәр, укучы, уку залы, формуляр, абонемент, стеллаж һ.б. яңа сүзләр белән таныштылар. Китапларны эзләү, уку залында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре дә искә төшерелде. “Татарстан – туган йортыбыз” темасына оештырылган күргәзмәдәге китапларны карадылар.

**Гыйбадуллина Айгөл, директор киңәшчесе**





## Гыйбрәтле фильм

18 нче ноябрь көнне балалар өчен мәдәният йортында зур экраннан “Суворовчы” дип аталган фильм карау оештырылды.

Фильм Суворов училищесында укучы Вова исемле малай турында. Аның сюжеты бик гыйбрәтле һәм куркыныч та. Малай җәйге каникулга авылга кайта. Ләкин әтисе сугышка китеп барган. Малай бу хәлне бик авыр кичерә. Тылда эшче көчләр җитмәгәнлектән, аңа ял итеп ятарга туры килми. Ул өлкәннәр белән беррәттән басуда эшли, уңыш җыярга булыша. Авылда өлкәннәр арасында килеп чыккан проблемаларны хәл итәргә булыша, участок инспекторына каракларны тотарга ярдәм итә.

Вова әлеге фильмда үзен искиткеч батыр итеп күрсәтә. Бөек Ватан сугышы елларында Вова шикелле яшүсмер малайлар үзләрен аямаганнар, тирә-юньдәге хәлләргә битараф булмаганнар. Аның куркусыз булуы аркасында күп икмәк бандитлардан тартып алына.

Әнә шундый кешелеклелек, батырлык сыйфатлары булган Вова безнең барыбызга да ошады.

**Бикбаева Руфинә, 7 нче сыйныф укучысы**

## Туган телем

Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Тел – тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Аңардан да көчле, татлы, назлы, ләззәтле тел бармы икән? Тел – ананың балага зур бүләге. Туган телне белү кирәк. Чөнки туган телдә синең әби – бабаларың, әти – әниләрең, халкың сөйләшкән һәм сөйләшә. Туган телгә хөрмәтле булганда гына кеше үз иленең, төбәгенең, гаиләсенең шәҗәрәсен, тарихын аңлый ала. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – һәр кешенең изге бурычы.

Минем туган телем – татар теле. Татарча минем телем ачылган, татарча бишек көйләре, әкиятләр тыңлап үстем. Шуның өчен дә ул безгә бик якын.

**Зәйнетдинова Гөлинә, 8 нче сыйныф укучысы**

*Ял сәгатьләрендә*







**Сәхифәне әзерләделәр:** туган тел һәм әдәбияты укытучысы, китапханә мөдире Садриева Н.З., туган тел һәм әдәбияты укытучысы Юнысова Р.К.

**Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта курса төп гомуми белем мәктәбе, Яшьләр урамы, 11**